ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Вөждан ирегә турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 552-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова, М.Х. Сәлахов, Р.Р. Шәмсетдинов тарафыннан кертелгән «Вөждан ирегә турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 552-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2518-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова,
М.Х. Сәлахов, Р.Р. Шәмсетдинов
тарафыннан кертелә

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу хакындагы карарны кабул итәргә вәкаләтле органга» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле органының Татарстан Республикасында территориаль органына» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле органга» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле органының Татарстан Республикасында территориаль органына» сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 статьяда:

а) 4 пунктта «федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 30 статьяда:

а) 3 пунктта «суд тәртибендә бетерелергә мөмкин» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле

органы яисә аның Татарстан Республикасында территориаль органы таләбе буенча суд тәртибендә бетерелергә тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында «теркәүче орган» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле органы яисә аның Татарстан Республикасында территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**аңлатма**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2024 елның 17 апрелендә үз көченә керә торган «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 апрелендәге 75-ФЗ номерлы Федераль закон «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда кулланыла торган дәүләт хакимиятенең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле органы исеменә карата терминологияне унификацияләү максатларында кабул ителде, ул «дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында карар кабул итүче орган», «федераль дәүләт теркәве органы», «федераль юстиция органы» дип аталган иде.

Кабул ителгән Федераль закон югарыда атап үтелгән дәүләт хакимияте органының исемнәре урынына «федераль башкарма хакимиятнең дини оешманы дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле органы» дигән бердәм терминны куллануны күздә тота.

Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.